ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы,
422577

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

29.03.2019г. Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48, № 15

с. Соболевсое

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында**

Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирерлек хәлгә китерү өчен эшләр башкаруны оештыру өчен,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Соболевский авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын игълан итәргә (алга таба – икеайлык).
2. Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын 2019 елга расларга. (1нче кушымта)
3. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Соболевский авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү буенча чаралар планын расларга. (2 нче кушымта).
4. Соболевский авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, якын-тирә территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга, икеайлык кысаларында оештырылган полигонга һәм чүплеккә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен йөк транспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә.
5. Урыннарда агачлар һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшен оештырырга.
6. Нинди хокукка карамастан, авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.

7. Бу карарны  Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә. Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Соболевский авыл җирлеге Башлыгы** **О.Н.Майорова**

Соболевский авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
29 март 2019 ел №15 карарына
1 нче кушымта

Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы

1. Майорова Ольга Николаевна- Соболевский авыл җирлеге Башлыгы
2. Мартышина Ирина Александровна- Соболевский авыл җирлеге Башкарма комитет сәркатибе
3. Фёдоров Николай Алексеевич – Чулпан 7 нче округ сайлау комиссиясе депутаты
4. Росихина Людмила Ивановна - Кармыш 4нче округ сайлау комиссиясе депутаты
5. Якимова Любовь Александровна – Соболевский авыл җирлеге мәдәният йорты мөдире

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Соболевский авыл җирлеге Башлыгы** **О.Н.Майорова**

Соболевский авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
29 март 2019 ел №15 карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту буенча чаралар**
**ПЛАНЫ**

| № | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Авыл җирлеген төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышы, Совет утырышлары үткәрү | 29.03.2019 | Авыл җирлеге Башлыгы, җирлек халкы |
| 2. | Каты көнкүреш калдыклары өчен дача хуҗалыклары белән килешүләр төзү.<br>Юл буе полосаларын җыештыру бердәм санитар көнен билгеләргә-чәршәмбе | 01.04. алып 31.05.2019елга кадәр | Сергеев А.<br><br>Авыл җирлеге Башлыгы,, учреждение,оешма җитәкчеләре |
| 3. | Сәүдә нокталарының якын-тирә территорияләрендә санитар нормаларның үтәлешен даими рәвештә тикшереп торуны оештырырга | даими | Авыл җирлеге Башлыгы,, полиция участок инспекторы |
| 4. | Полиция участок вәкаләтле вәкиле белән берлектә ТР санитар һәм табигать саклау законнарын бозуларны ачыклау һәм булдырмау буенча рейдлар үткәрергә | Атнага 1 тапкыр | Авыл җирлеге Башлыгы,, полиция участок инспекторы |
| 5. | Юл буе полосаларын җыештыру һәм торак пунктлар эчендә баганалар агарту | 20.04. алып 25.04.2019елга кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы,, учреждение,оешма җитәкчеләре |
| 6. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләр, оешмалар биналарының фасадларын ремонтлау | 01.05. алып 31.05.2019елга кадәр | учреждение,оешма җитәкчеләре |
| 7. | Йортларның фасадларын ремонтлау | 01.04. алып 31.05.2019 елга кадәр | Милекчеләр, авыл җирлеге территориясендә торак биналарны яллаучылар |
| 8. | Соболевский һәм Чулпан авылларында һәйкәлләрне төзекләндерү.<br>Чәчәкләр утырту. | 2019 ел 1 майга кадәр | Башкарма комитет һәм мәдәният хезмәткәрләре |
| 9. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү | 01.05.алып 31.05.2019 елга кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы,, оешма, учреждение җитәкчеләре, халык.. |
| 10. | Авыл җирлеге территориясендә чишмәләрне төзекләндерү | даими | Авыл җирлеге Башлыгы,, оешма, учреждение җитәкчеләре, халык. |
| 11. | Авыл җирлеге торак пунктларында яшел үсентеләр утырту. Клумбаларда чәчәкләр утырту. | 01.05. алып 31.05.2019 елга кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы,, оешма, учреждение җитәкчеләре, халык. |
| 12. | Су башняларын төзекләндерү | 01.04. алып 31.05.2019 елга кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | Җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (грейдирлау, чокыр ремонты) | 15.04. алып 31.05.2019елга кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы,, предприятие җитәкчеләре |
| 14. | Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен һәм төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү буенча комиссия утарын карап чыгу | даими | Төзекләндерү комитеты |

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Соболевский авыл җирлеге Башлыгы** **О.Н.Майорова**